Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №Х-5**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында” Х-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 15 гыйнварындагы 13 номерлы Указы, “Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында” 2020 елның 4 мартындагы ПУ-137 номерлы Указы кабул ителүгә бәйле рәвештә, муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында” ПУ-702 номерлы Указы, Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында” Х-4 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 16.11.2016 елгы XIII-6, 24.07.2017 елгы XX-6, 22.08.2017 елгы XXI-3 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакындагы Нигезләмәдә:

7 пунктның “в” пунктчасында “оешмалар” сүзеннән соң “, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта” сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлектәге 9.1 пунктын өстәргә:

“9.1. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турындагы, шулай ук керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматлар Россия Федерациясе Президенты раслаган Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган “БК белешмәләре” махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча тапшырыла, аңа сылтама шулай ук “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла.”;

13 пунктта “оешмалар” сүзеннән соң “, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта” сүзләрен өстәргә;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“15. Әлеге Нигезләмә нигезендә граждан яисә вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат тарафыннан тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, муниципаль хезмәткәр тарафыннан ел саен тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, шулай ук әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә беркетелә. Күрсәтелгән мәгълүматлар шулай ук электрон рәвештә сакланырга мөмкин.

Граждан яисә вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфага кандидат җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт

сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар биргән очракта, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгәндә, мондый мәгълүматлар күрсәтелгән затларга аларның язма гаризалары буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.”.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова